**Татарстан Республикасы**
**Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

"26" мая **2025** ел № 120

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Советының 2024 елның 20 декабрендәге 108 номерлы карары белән расланган Күлле-Киме авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

2024 елның 12 декабрендәге 89-ТРЗ номерлы «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 42 статьясына үзгәреш кертү хакында», 92-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Әтнә районы прокуратурасының 2025 елның 28 апрелендәге №02-08-02-2025/Прдп213-25 протесты нигезендә, Күлле-Киме авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Советының 2024 елның 20 декабрендәге 108 номерлы "Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында" карары белән расланган Күлле-Киме авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 3 бүлекнең 3.9 пунктында "2025 елның 1 гыйнварына" сүзләрен "2028 елның 1 гыйнварына" сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 16 бүлекнең 16.10 пунктындагы 3 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http://atnya.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Күлле-Киме авыл җирлеге башлыгы: Гәрәев Х.Х.